**Республика Татарстан**
**Шарлиареминское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Шәрләрәмә**
**авыл җирлеге**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31.01.2023ел** **№ 1**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «җирләү һәм җирләү эше турында» гы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турындагы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлегендә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә, 7793,48 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертү һәм билгеләү.

2.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитетының» җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында 31.01.2022 ел,2нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санау хакында

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO) урнаштырырга TATARSTAN.RU( Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Н.Н.Хуҗина

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмәавыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына
1 нче кушымта

2022 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4840,47 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1504,36 |
| Барлыгы | 7793,48 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмәавыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесенең
2023 елның 31 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нче кушымта

2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 1568,46 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3266,44 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1448,65 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1509,93 |
| Барлыгы | 7793,48 |